КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 июль г.Казань № 853

Татарстан Республикасы бюджетыннан массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән грантларны бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджетыннан массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән грантларны бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 18 июль, 853 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетыннан массакүләм мәгълүмат чараларында
һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы
дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү
һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны
гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән грантларны бирү
тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетыннан массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән грантларны (алга таба – грант) бирү механизмы билгеләнә.

1.2. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сентябрь, 821 нче карары белән расланган «2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – Программа) нигезендә эшләнде.

1.3. Грант массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бирелә.

Грантлар аны алучыларга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән максат өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына (алга таба – вәкаләтле орган) билгеләнгә тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән максатка каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – вәкаләтле орган.

1.4. Грантларның гомуми күләме елына 450 мең сум тәшкил итә, шулардан:

«Интернет» челтәре өчен иң яхшы медиаресурс проекты» номинациясе буенча – 150 мең сум күләмендә өч грант, шул исәптән I урын өчен – 70 мең сум, II урын

өчен – 50 мең сум, III урын өчен – 30 мең сум;

«Интернет» челтәрендә туган телнең кулланышын арттыруда иң яхшы интернет-акция проекты» номинациясе буенча – 150 мең сум күләмендә өч грант, шул исәптән I урын өчен – 70 мең сум, II урын өчен – 50 мең сум, III урын өчен – 30 мең сум;

«Социаль челтәрләрдә туган телне популярлаштыра/саклый торган иң яхшы проект» номинациясе буенча – 150 мең сум күләмендә өч грант, шул исәптән I урын өчен – 70 мең сум, II урын өчен – 50 мең сум, III урын өчен – 30 мең сум.

1.5. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

грант – массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыру өчен грант алучыларга бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы;

дәгъвачы – әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча грант алуга заявка (алга таба – заявка) биргән 18 яшьтән олырак Россия Федерациясе гражданы булган физик зат;

грант алучы – грант алуга конкурс нигезендә сайлап алуда (алга таба – конкурс нигезендә сайлап алу) җиңүче дип танылган дәгъвачы;

грант бирү турында килешү – вәкаләтле орган һәм грант алучы арасында вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган форма нигезендә төзелгән грант бирү турында килешү, аның нигезендә вәкаләтле орган грант алучының Россия кредит оешмасында ачылган счетына акча күчерә.

## II. Конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибе

2.1. Грант әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртип һәм сроклар нигезендә ел саен уздырыла торган конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелә.

2.2. Вәкаләтле орган, вәкаләтле органның конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү турында боерыгы кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә, вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында (https://digital.tatarstan.ru/), шулай ук Программаның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында (http://tel.tatar.ru) мәгълүмат урнаштыру юлы белән конкурс нигезендә сайлап алу турында игълан итә.

«Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат бирү характерындагы хәбәрдә конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү шартлары һәм сроклары, дәгъвачыларга карата таләпләр, документларны кабул итә башлау һәм тәгәлләү сроклары бирелә.

2.3. Конкурс нигезендә сайлап алу вәкаләтле орган тарафыннан төзелә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән грантлар буенча комиссия конкурсы (алга таба – конкурс комиссиясе) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе составына кимендә сигез кеше, шул исәптән вәкаләтле орган, массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре (килешү буенча) керә.

2.4. Дәгъвачылар түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максат өчен башка хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш;

конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен документлар бирелгән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага Татарстан Республикасы бюджетына грантларны, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән грантларны һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдындагы башка срогы чыккан бурычны кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы булмау;

конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен документлар бирелгән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмау.

2.5. Конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен дәгъвачылар конкурс нигезендә сайлап алу турында игълан ителгән датадан агымдагы елның 14 августында 18 сәгатькә кадәр вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

заявка;

вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык;

грант бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата грантларны (шул исәптән башка норматив хокукый актлар нигезендә бирелгән грантларны) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнәмгән бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджетына үз вакытында түләнмәгән башка бурычы булмавы турында, шулай ук дәгъвачының әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максат өчен башка хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавы турында гарантия хаты;

салым органының конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен документлар бирелгән көнгә кадәр 30 календарь көннән иртәрәк булмаган датага карата салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән проект.

Дәгъвачы вәкаләтле органга әлеге пунктта күрсәтелгән, сканерланган күчермәләрне яки документларның цифрлы фотокүчермәләрен (реквизитларны мәгълүмат укый торган машина белән танып белүне тәэмин итеп, сканерлау яки фотокүчермә алу юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы

документларны) тапшырырга хокуклы.

2.6. Әгәр конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга бер генә заявка да бирелмәгән булса, конкурс нигезендә сайлап алу уздырылмаган дип танала.

Конкурс нигезендә сайлап алу уздырылмаган дип тану турындагы карар конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

2.7. Вәкаләтле орган агымдагы елның 18 августына кадәр дәгъвачылар тарафыннан тапшырылган документларны карап тикшерә һәм дәгъвачыларга конкурс нигезендә сайлап алуда катнашырга рөхсәт итү яки рөхсәт итүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Дәгъвачыга конкурс нигезендә сайлап алуда баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

дәгъвачының әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

дәгъвачы тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртипнең 2.5 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

дәгъвачы тарафыннан документларның аларны кабул итү срогы тәмамланган көннән соң тапшырылуы.

Дәгъвачыларга конкурс нигезендә сайлап алуда катнашырга рөхсәт итү яки аларга рөхсәт итүдән баш тарту турында мәгълүмат вәкаләтле орган тарафыннан агымдагы елның 22 августына кадәр әлеге Тәртипнең 2.2 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән сайтларда урнаштырыла.

2.8. Дәгъвачы, әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, дәгъвачыларга конкурс нигезендә сайлап алуда катнашырга рөхсәт итү яки дәгъвачыларга рөхсәт итүдән баш тарту турында мәгълүмат урнаштырылган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көндә документларны кабат тапшырырга хокуклы.

2.9. Конкурс комиссиясе дәгъвачылар тарафыннан тапшырылган документларны карап тикшерә һәм агымдагы елның 8 сентябренә кадәр, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә заявкаларны бәяләү критерийлары нигезендә заявкаларны бәяләп, конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләрне билгели.

Әлеге критерийлар нигезендә конкурс комиссиясе әгъзалары, дәгъвачыларны күрсәтеп, җыйган баллар саны кимеп бара торган рангларга бүлеп, тәртип саны биреп, карап тикшерелгән заявкалар исемлеген төзи.

Заявкага түбәндәгеләрне бирү өчен:

номинация буенча I урын бирү өчен заявка кимендә 30 балл җыярга тиеш;

II урын өчен – кимендә 25 балл;

III урын өчен – кимендә 20 балл.

Конкурс комиссиясе, әлеге комиссия составының кимендә өчтән икесен тәшкил итә торган кворум булганда, утырышта катнашучы конкурс комиссиясе әгъзалары санынннан гади күпчелек тавышлар белән ачык тавыш биреп конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү турында карар кабул итә.

Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

Конкурс комиссиясенең конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү турында карары конкурс комиссиясе утырышы үткәрелгән көннән өч эш

көне эчендә конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләр күрсәтелгән беркетмә белән рәсмиләштерелә, аның аерылгысыз бер өлеше булган кушымтада конкурс комиссиясе утырышында заявкалары карап тикшерелгән дәгъвачылар (иң күп балл җыючыдан башлап, җыйган баллар саны буенча) күрсәтелә.

2.10. Вәкаләтле орган конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе нигезендә әлеге беркетмә расланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләргә грант бирү турында яисә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Вәкаләтле орган карары боерык белән рәсмиләштерелә.

2.11. Дәгъвачыга грант бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында каралган документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

дәгъвачы тарафыннан заявкада һәм әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән документларда бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

2.12. Әлеге Тәртипнең 2.10 пунктында күрсәтелгән, кабул ителгән карарлар нәтиҗәләре турында хәбәрнамә вәкаләтле орган тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә заявкада күрсәтелгән электрон почта адресына җибәрелә.

2.13. Вәкаләтле органның һәм конкурс комиссиясенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвачылар тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

## III. 3. Грантны күчерү һәм кире кайтару тәртибе һәм шартлары

3.1. Вәкаләтле орган конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләргә грант бирү турындагы карар нигезендә, агымдагы елның 29 сентябреннән дә соңга калмыйча, грант алучы белән вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган форма буенча грант бирү турында килешү төзи.

Грант бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр карала:

массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиа-проектларны гамәлгә ашыруга грант алуга грант алучының ризалыгы;

вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүгә грант алучының ризалыгы.

3.2. Грант вәкаләтле орган тарафыннан грант алучыга грант бирү турында килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә грант алучының Россия кредит оешмасында ачылган счетына акча күчерү юлы белән бирелә.

3.3. Грант вәкаләтле органның тиешле таләпләре алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш:

вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерү факты буенча грант алучы тарафыннан грант бирү шартлары

һәм тәртибе бозылу ачыкланган очракта;

грант алучы тарафыннан белә торып ялган белешмәләр бирү факты билгеләнгән очракта;

грант бирү турындагы килешүдә билгеләнгән срок эчендә грант бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта;

грант бирү турындагы килешүдә каралган срок эчендә грант бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта.

3.4. Әлеге Тәртипнең 3.3 пунктында билгеләнгән грантны кире кайтару сроклары бозылганда, вәкаләтле орган кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

## IV. Грант бирү шартларының үтәлешен контрольдә тоту

4.1. Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары грантлар бирүгә бүлеп бирелгән бюджет акчасын бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

4.2. Грант бирү нәтиҗәсе – массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыру.

4.3. Грант бирелгән елдан соң килә торган елның 1 октябренә кадәр грант алучы вәкаләтле органга вәкаләтле органның боерыгы белән расланган форма буенча грант бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап кертә.

Татарстан Республикасы бюджетыннан массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән грантларны бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры

______________________________________________
(Ф.И.Ат.ис.)

___________________________________ (дан, нан)
(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

______________________________________________

______________________________________________
(паспорт мәгълүматлары)

______________________________________________
(индекс, яшәү урыны адресы)

______________________________________________
(телефон номеры, электрон почта адресы)

Татарстан Республикасы бюджетыннан массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән грантны алуга
заявка

Заявка бирүче (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) _________________________
_____________________________________________________________________________

Элемтәгә керү өчен телефон _____________________________________________

Электрон почтасы _____________________________________________________

Шәһәр / торак пункт ___________________________________________________

Тәҗрибә һәм компетенция ______________________________________________

Проект номинациясе ___________________________________________________

Проект категориясе: яңа / булганын үстерү (кирәге астына сызарга)

Проектның исеме ______________________________________________________

Проектның кыскача тасвирламасы ____________________________________________
Проектны тормышка ашырудан көтелә торган социаль эффект ________________
_____________________________________________________________________________________
Проектның максаты (максатлары) һәм бурычлары ____________________________
Проектның географиясе _____________________________________________________
Проектны тормышка ашыру срогы ____________________________________________
Проектны тормышка ашыру чыгымнарын нигезләү ___________________________
Финанслашуның булу-булмавы _______________________________________________

Татарстан Республикасы бюджетыннан массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм аларның яшәеше мәсьәләләрен яктырту буенча медиапроектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән грантларны бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Заявкаларны бәяләү критерийлары

| Т/с | Заявкаларны бәяләү критерие исеме | Бәяләү, балл |
|---|---|---|
| 1. | Конкурста сайлап алу тематикасын чагылдыра торган эчтәлек | 0 – эчтәлек конкурста сайлап алу темасын чагылдырмый;<br>5 – эчтәлек конкурста сайлап алу тематикасын чагылдыра |
| 2. | Проектның социаль әһәмияте | 0 – проектның социаль әһәмияте түбән дәрәҗәдә булу;<br>3 – проектның социаль әһәмияте урта дәрәҗәдә булу;<br>5 – проектның социаль әһәмияте югары дәрәҗәдә булу; |
| 3. | Проектның мантыйкый бәйлелеге һәм гамәлгә ашырылуы, проектның чаралары аның максатларына, бурычларына һәм көтелә торган нәтиҗәләренә туры килүе | 0 – тәкъдим ителми;<br>5 – тәкъдим ителә |
| 4. | Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасы халыкларының башка телләрен үстерү һәм куллану өлкәсендә тәкъдим ителә торган карарларның нәтиҗәлелеге | 0 – тәкъдим ителә торган карарларның нәтиҗәлелеге түбән дәрәҗәдә булу;<br>3 – тәкъдим ителә торган карарларның нәтиҗәлелеге урта дәрәҗәдә булу;<br>5 – тәкъдим ителә торган карарларның нәтиҗәлелеге югары дәрәҗәдә булу |
| 5. | Проектның инновациялелеге | 0 – тәкъдим ителми;<br>5 – тәкъдим ителә |
| 6. | Проектны гамәлгә ашыру масштабы | 0 – проектның билгеләнгән территориаль колачлавы акланмый;<br>5 – проектның билгеләнгән территориаль колачлавы аклана |

| | | |
|---|---|---|
| 7. | Проектны гамәлгә ашыру чыгымнарының нигезле булуы | 0 – чыгымнар нигезләнми;<br>5 – чыгымнар нигезләнә |

______________________